ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДАНАУРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422951, Республика Татарстан,
Чистопольский район,
д.Данауровка, ул.Центральная, 20 «А»

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДАНАУРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422951, Татарстан Республикасы,
Чистай районы, Данауровка авылы,
Центральная урамы, 20 «А»

e-mail: Dnr.Ctp@tatar.ru тел. (84342) 5-71-38

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 7 2021 елның 12 мае

Данауровка авыл җирлеге Башкарма комитетының «2021-2024 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2021 елның 17 мартындагы 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү һәм эшкуарлык эшчәнлеген алып бару өчен кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан уңай икътисадый мохит булдыру максатларында, Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Данауровка авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 17 мартындагы 1 номерлы карары белән расланган «2021-2024 елларга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Данауровка авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. Программа паспортында «Чистай муниципаль районы халкын эш белән тәэмин итү программасы. Кредит акчалары һәм эшкуарларның үз акчалары. Җирле бюджет чараларын финанслау» сүзләрен түбәндәге сүзләргә алмаштырырга:
«Программаны финанслауның гомуми күләме җирле бюджет акчалары исәбеннән 4 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

(мең сум)

| Ел | Җирле бюджет акчалары |
|---|---|
| 2021 | 1 |
| 2022 | 1 |
| 2023 | 1 |
| 2024 | 1 |
| Барлыгы | 4» |

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 5 бүлек өстәргә:
«5. Программаны финанслау:
Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына методик, консультация-мәгълүмати ярдәм күрсәтү, шулай ук ярдәмнең финанс, мәгълүмати һәм башка рәвешләрен алу механизмнары турында мәгълүмат бирү максатында җирле бюджет акчалары исәбеннән түбәндәге чаралар финанслана:

(мең сум)

| Чара исеме | Акча күләме | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен методик ярдәмлекләр, мәгълүмати буклетлар, брошюралар, плакатлар, белешмәлекләр эшләү | 1 | 1 | 1 | 1»; |

1.3. Кушымта таблицасына түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен методик ярдәмлекләр, мәгълүмати буклетлар, брошюралар, плакатлар, белешмәлекләр эшләү | 1 | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2021-2024 | Үткәрелгән чаралар саны, бер. | 1 | 1 | 1 | 1 |

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга.

Данауровка авыл җирлеге
башлыгы В.К. Сәдретдинова